РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноября 2023г. г. Альметьевск №258

«Әлмәт муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир есте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, шулай ук Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлегендә хәвеф-хәтәр чыгу куркынычын камилләштерү» 2023 елның 24 мартындагы 14-Д24 номерлы беркетмәләре, «Судка шикаять бирү кысаларында шикаятьләрне карау турында һәм контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2023 елның 7 июлендәге 26-Д24 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Әлмәт муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 113 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 153 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 232 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир есте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге»

1. Торак пункт чикләрендә муниципаль контроль объектында һәм (яисә) җирле әһәмияттәге бер үк юлда (2 һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте) утыз календарь көн эчендә үлемгә китергән юл-транспорт һәлакәтләре фактлары.

2. Автомобиль транспортында, шәһәр җир есте электр транспортында юл йөрү кагыйдәләрен бозу фактлары, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында бер календарь ел дәвамында, алдагы календарь ел (1 юл-транспорт һәлакәте һәм аннан да күбрәк) белән чагыштырганда башкарылган фактлар.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов